# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге составына керүче Шәмәк торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№1 «26» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Шәмәк торак пунктында 2023 елның «26» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Шәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Шәмәк торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу
- Шәмәк торак пункты зираты территориясендә агачларны кисү
- Шәмәк торак пунктында юлларны кардан чистарту һәм грейдлау

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 199 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 114 кеше, 57,3 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 114 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0  граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР  КАБУЛ  ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Шәмәк торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлегенең Шәмәк торак пунктында  түбәндәге сорау буенча  узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк   авыл җирлеге Шәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда  500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Шәмәк торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерү өчен материаллар сатып алу
- Шәмәк торак пункты зираты территориясендә агачларны кисү
- Шәмәк торак пунктында юлларны кардан чистарту һәм грейдлау

3. Әлеге карарны Шәмәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәмәк авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе                                                                 И.Н.Зиятдинов